ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫН ХӘЛ ИТҮ

2024 елда граждannardan үзара салым кертү турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге Бакташ авылында

2023 елның 20 октябре № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегендә гражданнарның җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Бакташ авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, контракт буенча хезмәт итүче Россия Федерациясе Кораллы Көчләре хәрбиләре, мобилизацияләнгән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрергә: торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту.

3. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru/Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatar.ru, Бакташ, Солнечная ур., 7 нче йорт мәгълүмат стендында кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә халыкка җиткерергә.

4. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Халык җыенында рәислек итүче,

Татарстан Республикасы

Яңа Чишмә муниципаль районы

Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.И. Назмутдинова

